Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

№7-3 « 12 » октябрь 2020 ел

«Җир салымы турында»

1 статья. Гомуми нигезләмәләр

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә әлеге карар белән Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләүгә җир салымы (алга таба - салым) билгеләнә һәм гамәлгә кертелә.

2 статья. Салым ставкалары

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Антонов авыл җирлеге территориясендә җир салымының салым ставкалары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

1.1. Җир кишәрлекләренә карата 0,3%:
- торак пунктларда авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган авыл хуҗалыгы кулланылышы зоналары составындагы җирләргә яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә кертелгән;
- торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына керми торган җир кишәрлегенә хокукы өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш), индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләрендә файдаланылмый торган затлар;
- оборонаны, куркынычсызлыкны һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән затлар;

1.2. **0,04%** - җирле үзидарә органнары, казна, бюджет һәм автоном учреждениеләр белән торак пункт җирләре категориясенә кертелгән җир кишәрлекләренә карата җирле бюджеттан финанслана торган җир кишәрлекләренә карата;

1.3. **0,2%** - республика бюджетыннан финанслана торган казна, бюджет һәм автоном учреждениеләр белән торак пункт җирләре категориясенә кертелгән җир кишәрлекләренә карата;

1.4. **0,05%** - сәнәгать һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясенә кертелгән гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата 1-3%;

1.5. **1,5%** - башка җир кишәрлекләренә карата.

3 статья. Салым ташламалары

Түбәндәге категория салым түләүчеләрне җир салымын түләүдән азат итү:

- гражданнар күмелгән җир кишәрлекләренә карата оешмалар;

- физик затлар – ирекле янгын сагы хезмәткәрләре һәм ирекле янгын сүндерүчеләр, әлеге статусны раслаучы документы булган.

4 статья. Әлеге Карарның үз көченә керүе

Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түгел, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Әлеге карарны Ямбакты авылы, пунктларында, шулай ук Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм (https://pravo.tatarstan.ru/) рәсми хокукый мәгълүмат сайтында һәм (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырырга.

Әлеге карар үз көченә кергән көннән «Җир салымы турында» 2015 елның 12 октябрендәге 2-1 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге советы карарын үз көчен югалткан дип танырга (№ 34 от 01.06.2017 г., №92 от 03.07.2019 г., №101-2 от 22.10.2019 г.,№104 от 19.11.2019г., №112 от 23.01.2020г номерлы кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән).

Ямбакты авыл җирлеге башлыгы И.Ә.Гәләветдинов.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ЯМБУХТИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

СОВЕТ ЯМБУХТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ